ГЛАВА
АГРЫЗСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

25.06.2025 Әгерҗе шәһәре № 57

Муниципаль хезмәткәрләр биләгән очракта муниципаль хезмәткәрләр керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиешле Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында билгеләнгән муниципаль хезмәт вазыйфалары Исемлеге раслау турында

«Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 8, 8.1 статьялары, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 02 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар һәм башка затлар чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында» 03.12.2012 елның 230-ФЗ номерлы Федераль законы, «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы» 25.06.2013 елның 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. Муниципаль хезмәткәрләр биләгән вакытта муниципаль хезмәткәрләр керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиешле Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында билгеләнгән муниципаль хезмәт вазыйфалары Исемлеген расларга (кушымта итеп бирелә).

2. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының кадрлар бүлегенә муниципаль хезмәткәрләр биләгән вакытта муниципаль хезмәткәрләр үз хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиешле муниципаль хезмәт вазыйфалары Исемлегенә кертелгән муниципаль

хезмәткәрләргә имза салырга.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (http://agryz.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Муниципаль район башлыгы Л.Ф. Нургаянов

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башлыгының 25.06.2025 елның 57 номерлы карарына кушымта

муниципаль хезмәткәрләр билгән вакытта муниципаль хезмәткәрләр керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиешле Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында билгеләнгән муниципаль хезмәт вазыйфалары Исемлеге

## I. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советы аппараты муниципаль хезмәте вазыйфалары

**1. Муниципаль хезмәт вазыйфаларының югары төркеме:**
- аппарат җитәкчесе.

**2. Муниципаль хезмәт вазыйфаларының төп төркеме:**
- оештыру бүлеге башлыгы;
- гомуми бүлек башлыгы.

**3. Муниципаль хезмәт вазыйфаларының әйдәп баручы төркеме:**
- муниципаль район башлыгы ярдәмчесе.

**4. Муниципаль хезмәт вазыйфаларының өлкән төркеме:**
- оештыру бүлеге баш белгече;
- гомуми бүлекнең баш белгече.

## II. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының муниципаль хезмәт вазыйфалары

**1. Муниципаль хезмәт вазыйфаларының югары төркеме:**
- Башкарма комитет җитәкчесе;
- Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары;
- Башкарма комитетның эшләр идарәчесе.

**2. Муниципаль хезмәт вазыйфаларының төп төркеме:**
- бухгалтерлык исәбе һәм хисаплылык бүлеге башлыгы;
- икътисадый үсеш бүлеге башлыгы;
- төзелеш, архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлеге башлыгы;
- юридик бүлеге башлыгы;
- кадрлар бүлеге башлыгы;
- гомуми бүлек башлыгы;
- архив бүлеге башлыгы;
- граждан хәле актларын теркәү бүлеге башлыгы;
- социаль үсеш бүлеге башлыгы.

**3. Муниципаль хезмәт вазыйфаларының әйдәп баручы төркеме:**
- Башкарма комитет җитәкчесенең ярдәмчесе;

- муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алу секторы мөдире;
- торак сәясәте һәм торак-коммуналь хуҗалык секторы мөдире;
- мәгълүматлаштыру һәм мәгълүмати иминлек секторы мөдире;
- опека һәм попечительлек секторы мөдире;
- балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау секторы мөдире.

**4. Муниципаль хезмәт вазыйфаларының өлкән төркеме:**

- бухгалтерлык исәбе һәм хисаплылык бүлегенең баш белгече;
- икътисадый үсеш бүлегенең баш белгече;
- төзелеш, архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлегенең баш белгече;
- юридик бүлекнең баш белгече;
- кадрлар бүлегенең баш белгече;
- гомуми бүлекнең баш белгече;
- архив бүлегенең баш белгече;
- граждан хәле актларын теркәү бүлегенең баш белгече;
- социаль үсеш бүлеге баш белгече;

муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алу секторының баш белгече;

- опека һәм попечительлек секторының баш белгече;
- балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау секторының баш белгече;
- гомуми бүлекнең әйдәүче белгече;
- балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау секторының әйдәп баручы белгече.

## III. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре Палатасы муниципаль хезмәт вазыйфалары

**1. Муниципаль хезмәт вазыйфаларының югары төркеме:**

- рәис;
- рәис урынбасары.

**2. Муниципаль хезмәт вазыйфаларының төп төркеме:**

- контроль һәм исәпкә алу бүлеге башлыгы.

**3. Муниципаль хезмәт вазыйфаларының өлкән төркеме:**

- контроль һәм исәпкә алу бүлегенең баш белгече.

## IV. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы муниципаль хезмәт вазыйфалары

**1. Муниципаль хезмәт вазыйфаларының югары төркеме:**

- рәис;
- рәис урынбасары.

**2. Муниципаль хезмәт вазыйфаларының төп төркеме:**

- бюджет бүлеге башлыгы;
- исәпкә алу һәм хисаплылык бүлеге башлыгы;

- икътисад тармакларын мәгълүматлаштыру һәм финанслау бүлеге башлыгы.

**3. Муниципаль хезмәт вазыйфаларының әйдәп баручы төркеме:**

- исәпкә алу һәм хисаплылык бүлеге башлыгы урынбасары;
- бюджет бүлеге секторы мөдире.

**4. Муниципаль хезмәт вазыйфаларының өлкән төркеме:**

- исәпкә алу һәм хисаплылык бүлегенең баш белгече;
- икътисад тармакларын мәгълүматлаштыру һәм финанслау бүлегенең баш белгече.

## V. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Әгерҗе шәһәре» муниципаль берәмлеге вазыйфасы

**1. Муниципаль хезмәт вазыйфаларының югары төркеме:**

- Башкарма комитет җитәкчесе;
- Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары.

**2. Муниципаль хезмәт вазыйфаларының төп төркеме:**

- оештыру бүлеге башлыгы.

**3. Муниципаль хезмәт вазыйфаларының өлкән төркеме:**

- оештыру бүлеге баш белгече.

## VI. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы авыл җирлекләре башкарма комитетлары вазыйфасы

**1. Муниципаль хезмәт вазыйфаларының югары төркеме:**

- Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары.

**2. Муниципаль хезмәт вазыйфаларының кече төркеме:**

- белгеч.